**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Вәрәшбаш авыл җирлегенә керүче Иске Вәрәш авылы**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№ 2** **09.12.2019 ел**

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлеге составына керүче Иске Вәрәш торак пунктына 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Вәрәшбаш авыл җирлегенә караган Иске Вәрәш торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

**1.** Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Иске Вәрәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елга 700 (җиде йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 350 (өч йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертергә.

**2.** Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Иске Вәрәш авылында беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, Иске Вәрәш авылында рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;
- Иске Вәрәш авылында рәсми һәм мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыру
- Иске Вәрәш авылы территориясен төзекләндерүне оештыру;
- Иске Вәрәш авылы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу;
- Иске Вәрәш авылында ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- Иске Вәрәш торак пункты чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү;
- Иске Вәрәш торак пункты чикләрендә юл эшчәнлеге;
- Иске Вәрәш авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;
- җирлекнең территориаль планлаштыру документларын әзерләү һәм раслау;

- Иске Вәрәш т. п. территориясендә яшәүче күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тору буенча чараларны гамәлгә ашыруга.

**3.** Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга һәм Мөслим муниципаль районы, Иске Вәрәш авылы, Чишмә урамы, 10а йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә.

**4.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Вәрәшбаш авыл җирлеге башлыгы** **З.М.Маннапова**